ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22.01.2025** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районы Советы аппараты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының «Биектау муниципаль районы Советы аппараты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 20 номерлы карарына (10.02.2022 №11, 21.11.2023 №208, 15.08.2024 №109 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 өлешнең 5.2 пунктында «электрон адрес» сүзләрен «, электрон почта адресы йә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланганда шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 5 өлешнең 5.3 пунктында «электрон адрес» сүзләрен «электрон почта адресы йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 5 өлешнең 5.6 пунктында (почта, электрон) сүзләрен «(почта, электрон почта, йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 10 өлешне төшереп калдырырга;

1.5. 11 өлешнең 11.3 пунктын «электрон почта адреслары» сүзләреннән соң «йә 4 нче кушымта нигезендә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы,» сүзләре белән тулыландырырга;

1.6. 11 өлешнең 11.6 пунктында «(84365) 3-33-44» телефон номерын «8(84365) 2-30-67» номерына алмаштырырга;

1.7. 11 өлешнең 11.3 пунктында «4 нче кушымта нигезендә» сүзләрен «йә 4 нче кушымта нигезендә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы,» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә.

Р.Ф. Хисамутдинов